ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

# КАРАР

« 12 » май 2016 ел № 534

**«Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары турында» Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2013 елның 23 сентябрендәге 1218 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Президенты Указын һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын үтәү йөзеннән Арча муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга өстәмә компенсация бирү тәртибенә түбәндәге эчтәлекле пункт өстәп, үзгәрешләр кертергә:

Республика үзәге бүлекчәләренә матди ярдәм (компенсация түләүләре) Россия Федерациясе Пенсия фондыннан, шул исәптән ведомствоара электрон багланышлар бердәм системасын һәм аңа тоташтырыла торган ведомствоара мәгълүмати бәйләнешнең региональ системаларын кулланып, эш бирүче (имиңләштерүче) физик зат файдасына исәпләнгән түләүләр һәм башка бүләкләүләр суммасы турында белешмәләр алырга мөмкинлек бирә торган мәгълүмати бәйләнешне керткәннән соң, компенсацияне билгеләү аның гаризасында күрсәтелгән ризалыгы буенча башкарыла.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшерен торуны «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» МКУ җитәкчесе Ф.Р. Исмәгыйлевка йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе И.Ә.галимуллин